**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Сапеевского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального**
**района**

ул. Школьная, д.53В, село Сапеево,
Азнакаевского муниципального района, 423326
Тел. (факс) (8-85592) 44-2-40, факс 44-2-83
Sap.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Сэпэй авыл**
**җирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**

Школьная урамы , 53В, Сэпэй авылы
Азнакай муниципаль районы, 423326
Тел. (факс) (8-85592) 44-2-40
Sap.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» ноябрь 2021 ел № 4

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Мачаклы-Баш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принципларының турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар итәм:

1.Мачаклы-Баш авылы Урман буе урамы 1 йорттан 38А йортка кадәр, теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Мачаклы-Баш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2022 елның 12 ноябрендә 14.00 сәгатькә билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«Сез, 2023 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән, махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаиләләр, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 175 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Мачаклы-Баш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Мачаклы-Баш авылында юлларны чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен карны механикалаштырып җыю буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (мәчет, авыл клубы, ФАП һәм балалар бакчасы территориясе), территорияне механикалаштырылган чабу буенча хезмәтләр өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу, территорияне санитар чистарту, территорияләрне яшелләндерү чаралары) Мачаклы-Баш авылында территорияне санитар чистарту буенча хезмәт күрсәтү ;

- Мачаклы-Баш авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү).

« РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сәпәй авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык Ф.Г.Галиева